Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге составына кергән Ачы торак пункты

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 20 октябреннән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге Ачы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге Ачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кеше, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку бүлеге формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыны/ирләре азатителә, 500 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү белән килешәсезме, бу сумманың 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидлары, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр түли.
2. Алган акчаларны Ачи авылының скважина өчен су насосы (аны сатып алу, күчереп йөртү, урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) сатып алуга һәм вак таш өслекле юлларга чокырлы юл ремонтлауга (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Чишмә авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Әхмәтов